| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ**
10.06.2024

Казан ш.

**БОЕРЫК**
№01-05/159-пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен үз эченә алган белешмәләрдән файдалануга бәйле булып, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 7 февралендәге 132 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын һәм вазыйфаи затларын дәүләт серенә кертү кагыйдәләре нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен үз эченә алган белешмәләрдән файдалануга бәйле булып, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен үз эченә алган белешмәләрдән файдалануга бәйле булып, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2019 елның 29 июлендәге 01-05/168-пр номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2019 елның 29 июлендәге 01-05/168-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вазыйфаи бурычларны үтәү

дәүләт серен үз эченә алган белешмәләрдән файдалануга бәйле булып, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 25 февралендәге 01-05/65-пр номерлы.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.Ш.Борһанов

Татарстан Республикасы Дәүләт
техник күзәтчелек идарәсенең
10.06.2024 № 01-05/159-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен үз эченә алган белешмәләрдән файдалануга бәйле булып, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

| т/с | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| 1 | Әйдәп баручы киңәшче – мобилизация эше буенча әйдәп баручы киңәшче |